МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

№ 204/о

«08» 12 2020

БОЕРЫК

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 26 июнендәге 99/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 26 июнендәге 99/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлеккә, дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

Министр М.М.Айзатуллин

Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 2020 елның 8
декабрендәге 204/о номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 26 июнендәге 99/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.2 пунктта «дәүләт хезмәте күрсәтү турында» сүзләреннән соң «, шулай ук РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнүне һәм (яки) проект документларын әзерләүне гамәлгә ашырган зат» сүзләрен өстәргә;

2 бүлектә:

2.4 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасындагы 4 пунктта «21 эш көне» сүзләрен «30 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

2.14 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның да чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

2) хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында, шул исәптән объект хезмәткәрләре ярдәме белән дә, бүлмәләр буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

3) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

4) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларның хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү;

7) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, озата йөри торган этне кертү;

9) хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларга һәм әлеге пунктның 3-6 пунктчаларында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы;

3 бүлектә:

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«11. техник хатаны төзәтү»;

3.3 пунктның өченче абзацында «өч эш көне» сүзләрен «бер эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

3.5 пунктның өченче абзацында «гариза тапшырыла» сүзләрен «документлар тапшырыла» сүзләренә алмаштырырга;

3.7.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.7.2. Нигезләмәнең 35 пункты нигезендә, дәүләт экспертизасын үткәрү барышында проект документтарында һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләрендә бәяләмә әзерләргә мөмкинлек бирми торган җитешсезлекләр (белешмәләрнең, тасвирламаларның, исәпләмәләрнең, сызымнарның, схемаларның һ.б. булмавы яисә тулы булмавы) ачыкланган очракта, «ТР Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе Мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган җитешсезлекләр турында хәбәр итә.

Җитешсезлекләрне бетерү срогы мөрәҗәгать итүче тарафыннан капиталь төзелеш торак объектларына карата проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрү турында хәбәр

алынганнан соң биш эш көненнән дә артмый (яисә башка очракларда, мөрәҗәгать итүче тарафыннан хәбәр алынган көннән соң тугыз эш көненнән дә артмый).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар килешү имзаланган һәм дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү кертелгән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: локаль эксперт бәяләмәсе төзү, Мөрәҗәгать итүчегә җитешсезлекләр турында белдерү җибәрү.»

3.8.1 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар капиталь төзелешнең торак объектларына карата проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздырылганда Мөрәҗәгать итүче тарафыннан җитешсезлекләре бетерелгән, үзгәртелгән документлар тапшырылган көннән башлап биш эш көне эчендә (яисә, башка очракларда, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан җитешсезлекләре бетерелгән, үзгәртелгән документлар тапшырылган көннән башлап ун эш көне эчендә) гамәлгә ашырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.13 пункт өстәргә:

«3.13. Техник хатаны төзәтү тәртибе.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсен үзгәртеп рәсмиләштерү элегрәк бирелгән бәяләмәдә җибәрелгән техник хаталарны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) бетерү белән бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсен үзгәртеп рәсмиләштерү турында теркәлгән гариза (тәкъдим ителә торган форма әлеге Административ регламентка 7 нче кушымтада китерелгән), техник хатасы булган дәүләт экспертизасы бәяләмәсен һәм мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен раслый торган документны теркәп гамәлгә ашырыла.

3.13.1. «ТР Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм терки;

«ТР Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе җитәкчесе гаризаны караганнан соң, җитәкче дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертү турында яки үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында җавап хаты әзерләү турында резолюция имзалый, башкару өчен җаваплы затны билгели.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза алынган вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән, башкару өчен җаваплы белгечкә тапшырылган гариза.

3.13.2. Җаваплы белгеч:

«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» ДАУ җитәкчесенең дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертү яки үзгәрешләр кертүдән баш тарту турындагы боерыгы проектын әзерли;

«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» ДАУ җитәкчесе боерыгы проектын

«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» ДАУ җитәкчесенә килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза җибәрелгән мизгелдән бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: «Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» ДАУ җитәкчесенә килештерү өчен юнәлдерелгән боерык проекты.

3.13.3. «Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» ДАУ җитәкчесе дәүләт экспертизасы бәяләмәсен үзгәртеп рәсмиләштерү яки дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерык раслый. Кул куелган боерык җаваплы белгечкә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура проектны раслауга алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасы бәяләмәсен үзгәртеп рәсмиләштерү яки дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерык.

3.13.4. Дәүләт экспертизасы бәяләмәсен үзгәртеп рәсмиләштерү турында боерык чыгарылган очракта, «Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесенең җаваплы белгече, Бәяләмәләрнең бердәм дәүләт реестры дәүләт мәгълүмат системасының реестр бүлеге өлешендә проект әзерли һәм аны Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрын алып бару һәм аларда булган белешмәләрне һәм документларны бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 22 февралендәге 115/пр номерлы боерыгы (алга таба – Тәртип) белән расланган Тәртипнең 32 пунктының «а» пунктчасы, 34 һәм 35 пунктлары таләпләре нигезендә реестрны алып баруның мәгълүмат системасында терки.

3.13.5. Техник хатаны төзәтү Тәртипнең 29-40 пунктлары таләпләре нигезендә «Россия Баш дәүләт экспертизасы» ФАУ тарафыннан башкарыла.

3.13.6. Бәяләмәләрнең бердәм дәүләт реестры дәүләт мәгълүмат системасына үзгәрешләр керткәннән соң, җаваплы белгеч рәсмиләштерелгән бәяләмәне яисә дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында җавап бирә (җибәрә).

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән, техник хатасы төзәтелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе».

Административ регламентка 1 нче кушымтада:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Проект документларына һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрү вакыты 30 эш көненнән артмаска тиеш.

Капиталь төзелешнең торак объектларына карата, шул исәптән кертеп-янкорма итеп төзелгән торак булмаган бинаалары булганнарына карата да,

проект документларына һәм инженерлык эзләнүләр нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы 20 эш көне дәвамында үткәрелә.

Дәүләт экспертизасын үткәрү вакыты Заказчының язмача мөрәҗәгате нигезендә 20 эш көненә кадәр озайтылырга мөмкин.

Башкаручы хезмәт күрсәтүне вакытыннан алда тәмамларга һәм Заказчыга эш нәтиҗәсен – бәяләмә бирергә хокуклы.»;

Административ регламентка 2 нче кушымтада:

2.1-2.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Нигезләмә нигезендә, экспертиза бәясе 24 000 сум 00 тиен тәшкил итә, шул исәптән 20% ставка буенча өстәмә хак салымы (өстәмә хак салымы) – 4 000 сум 00 тиен;

2.2. Хезмәткә түләү дәүләт экспертизасының нәтиҗәсе нинди булуга бәйсез рәвештә түләнә.»;

2.3 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

5 нче бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

8.6 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

килешүгә кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

Административ регламентка 3 нче кушымтада:

I бүлегендә:

10-11 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. мөрәҗәгать итүченең төзүче оешма, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче оешма, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

11. проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүне башкару эшләрен үтәүче зат анда әгъза булып торган архитектура-төзелештә проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче оешмага, техник заказчыга, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче затка тапшыру көненә гамәлдә булган яки дәүләт экспертизасына документларны тапшырган алдагы датадан соң бер айдан артык булмаган

чорда гамәлдә булган өземтә, әгәр төзүче оешма, башка зат (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда) бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат булып торса (Россия Федерациясе законнары нигезендә проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнү эшләрен башкаручы затның архитектура-төзелештә проектлау өлкәсендә һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителсә). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре төзүче оешмага 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче оешмага (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ;»;

20 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«федераль башкарма хакимият органы җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе җитәкчесенең, «Роскосмос» космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе җитәкчесенең, «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясе җитәкчесенең, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесе – тиешле бюджет акчаларын баш бүлүче булып торган затның капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп коруның смета бәясен һәм аның егәрлеген төзелеш этаплары буенча бүлүне күздә тоткан этаплап башкару турында барлык этаплар буенча объектны төзү, үзгәртеп коруның гомуми смета бәясенең капиталь төзелеш объектының гомуми егәрлеген саклап, объект төзелешенең билгеләнгән күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәясен арттырмавын раслый торган карары (акты) яисә, төзелеше, үзгәртеп корылышы дәүләт компанияләре һәм корпорацияләре акчасы хисабыннан гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүнең, үзгәртеп коруның аерым этабына карата проект документлары әзерләнгән очракта, – дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) әлеге карары (акты)»;

түбәндәге эчтәлекле 23 пункт өстәргә:

«23. дәүләт (муниципаль) милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырган очракта, дәүләт (муниципаль) контрактларны тиешле

гавами-хокукый оешма исеменнән төзү һәм үтәү буенча дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге органнар затыннан дәүләт (муниципаль) заказчылар булып торган дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» комос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджетка карамаган фондлар белән идарә итү органы, җирле үзидарә органы һәм әлеге органнар аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән яки әлеге органнар аларга карата тиешле гавами-хокукый оешманың мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр белән (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта) төзелгән килешү.»;

II бүлектә:

9-10 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. мөрәҗәгать итүченең төзүче оешма, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче оешма, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

10. проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүне башкару эшләрен үтәүче зат анда әгъза булып торган архитектура-төзелештә проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче оешмага, техник заказчыга, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче затка тапшыру көненә гамәлдә булган яки дәүләт экспертизасына документларны тапшырган алдагы датадан соң бер айдан артык булмаган чорда гамәлдә булган өземтә, әгәр төзүче оешма, башка зат (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда) бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат булып торса (Россия Федерациясе законнары нигезендә проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнү эшләрен башкаручы затның архитектура-төзелештә проектлау өлкәсендә һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителсә). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре төзүче оешмага 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен төзүче оешмага (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә

булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ;»;

түбәндәге эчтәлекле 13-14 пунктлар өстәргә:

«13. хәтәр җитештерү объектының куркынычсызлыгын нигезләү, мондый нигезләүгә сәнәгый куркынычсызлык экспертизасы бәяләмәләре реестрына кертелгән сәнәгый куркынычсызлык экспертизасының уңай бәяләмәсен теркәп, әгәр хәтәр җитештерү объектының куркынычсызлыгын нигезләүне әзерләү һәм мондый нигезләүгә сәнәгый куркынычсызлык экспертизасын уздыру «Хәтәр җитештерү объектларының сәнәгый куркынычсызлыгы турында» 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законда каралган булса;

14. дәүләт (муниципаль) милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырган очракта, дәүләт (муниципаль) контрактларны тиешле гавами-хокукый оешма исеменнән төзү һәм үтәү буенча дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге органнар затыннан дәүләт (муниципаль) заказчылар булып торган дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» комос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджетка карамаган фондлар белән идарә итү органы, җирле үзидарә органы һәм әлеге органнар аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән яки әлеге органнар аларга карата тиешле гавами-хокукый оешманың мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр белән (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта) төзелгән килешү.»;

III бүлектә:

4-5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. мөрәҗәгать итүченең төзүче оешма, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче оешма, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

5. проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүне

башкару эшләрен үтәүче зат анда әгъза булып торган архитектура-төзелештә проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче оешмага, техник заказчыга, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче затка тапшыру көненә гамәлдә булган яки дәүләт экспертизасына документларны тапшырган алдагы датадан соң бер айдан артык булмаган чорда гамәлдә булган өземтә, әгәр төзүче оешма, башка зат (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда) бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат булып торса (Россия Федерациясе законнары нигезендә проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнү эшләрен башкаручы затның архитектура-төзелештә проектлау өлкәсендә һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителсә). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре төзүче оешмага 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен төзүче оешмага (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ;»;

түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8. дәүләт (муниципаль) милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырган очракта, дәүләт (муниципаль) контрактларны тиешле гавами-хокукый оешма исеменнән төзү һәм үтәү буенча дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге органнар затыннан дәүләт (муниципаль) заказчылар булып торган дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» комос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджетка карамаган фондлар белән идарә итү органы, җирле үзидарә органы һәм әлеге органнар аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән яки әлеге органнар аларга карата тиешле гавами-хокукый оешманың мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр белән (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта) төзелгән килешү;».

IV бүлектә:

10-11 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. мөрәҗәгать итүченең төзүче оешма, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче оешма, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

11. проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүне башкару эшләрен үтәүче зат анда әгъза булып торган архитектура-төзелештә проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче оешмага, техник заказчыга, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче затка тапшыру көненә гамәлдә булган яки дәүләт экспертизасына документларны тапшырган алдагы датадан соң бер айдан артык булмаган чорда гамәлдә булган өземтә, әгәр төзүче оешма, башка зат (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда) бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат булып торса (Россия Федерациясе законнары нигезендә проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнү эшләрен башкаручы затның архитектура-төзелештә проектлау өлкәсендә һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителсә). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре төзүче оешмага 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен төзүче оешмага (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ;»

20 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 26 пункт өстәргә:

«26. дәүләт (муниципаль) милек объектларына бюджет инвестицияләрен

гамәлгә ашырган очракта, дәүләт (муниципаль) контрактларны тиешле гавами-хокукый оешма исеменнән төзү һәм үтәү буенча дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге органнар затыннан дәүләт (муниципаль) заказчылар булып торган дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» комос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджетка карамаган фондлар белән идарә итү органы, җирле үзидарә органы һәм әлеге органнар аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән яки әлеге органнар аларга карата тиешле гавами-хокукый оешманың мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр белән (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта) төзелгән килешү.»;

V бүлектә:

9-10 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. мөрәҗәгать итүченең төзүче оешма, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче оешма, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

10. проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүне башкару эшләрен үтәүче зат анда әгъза булып торган архитектура-төзелештә проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче оешмага, техник заказчыга, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче затка тапшыру көненә гамәлдә булган яки дәүләт экспертизасына документларны тапшырган алдагы датадан соң бер айдан артык булмаган чорда гамәлдә булган өземтә, әгәр төзүче оешма, башка зат (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда) бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат булып торса (Россия Федерациясе законнары нигезендә проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнү эшләрен башкаручы затның архитектура-төзелештә проектлау өлкәсендә һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителсә). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре төзүче оешмага 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм

(яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен төзүче оешмага (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ;»

19 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. федераль башкарма хакимият органы җитәкчесенең (яисә ышаныч нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе җитәкчесенең, «Роскосмос» космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе җитәкчесенең, «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясе җитәкчесенең, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесе – тиешле бюджет акчаларын баш бүлүче булып торган затның капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп коруның смета бәясен һәм аның егәрлеген төзелеш этаплары буенча бүлүне күздә тоткан этаплап башкару турында барлык этаплар буенча объектны төзү, үзгәртеп коруның гомуми смета бәясенең капиталь төзелеш объектының гомуми егәрлеген саклап, объект төзелешенең билгеләнгән күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәясен арттырмавын раслый торган карары (акты) яисә, төзелеше, үзгәртеп корылышы дәүләт компанияләре һәм корпорацияләре акчасы хисабыннан гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүнең, үзгәртеп коруның аерым этабына карата проект документлары әзерләнгән очракта, – дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) әлеге карары (акты);»;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. проект документларын кабат кулланыла торган проект документларыннан файдаланып әзерләгән очракта, шулай ук документлар тапшырыла:

кабат кулланыла торган проект документларына карата уңай экспертиза бәяләмәсе;

үзгәрешләр кертелмәгән һәм кабат кулланыла торган проект документларына тулысынча туры килә торган проект документларының дәүләт экспертизасына тапшырылган бүлекләрен күрсәтеп, белешмә;

проектлана торган капиталь төзелеш объектын билгеләнешенең һәм проект егәрлегенең аналогик булуын һәм мондый капиталь төзелеш объектын төзүне гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территориядәге табигый һәм башка төр шартларның капиталь төзелеш объектының билгеләнешенә һәм

проект егәрлегенә һәм беренчел куллану өчен әзерләнгән, проектлау өчен кулланылган кабат кулланылышлы проект документларында исәпкә алынган территория шартларына туры килүен раслый торган документ, әгәр Россия Федерациясе законнарында проект документларын кабат кулланыла торган проект документларын мәҗбүри файдаланып әзерләү турындагы таләп билгеләнгән булса;»;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. дәүләт (муниципаль) милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырган очракта, дәүләт (муниципаль) контрактларны тиешле гавами-хокукый оешма исеменнән төзү һәм үтәү буенча дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге органнар затыннан дәүләт (муниципаль) заказчылар булып торган дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» комос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджетка карамаган фондлар белән идарә итү органы, җирле үзидарә органы һәм әлеге органнар аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән яки әлеге органнар аларга карата тиешле гавами-хокукый оешманың мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр белән (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта) төзелгән килешү;»;

25-26 пунктларны үз көчен югалткан дип таныргa;

VI бүлектә:

7-8 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. мөрәҗәгать итүченең төзүче оешма, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче оешма, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

8. проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүне башкару эшләрен үтәүче зат анда әгъза булып торган архитектура-төзелештә проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче оешмага, техник заказчыга, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче затка тапшыру көненә гамәлдә булган яки дәүләт экспертизасына документларны тапшырган алдагы датадан соң бер айдан артык булмаган чорда гамәлдә булган өземтә, әгәр төзүче оешма, башка зат (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган

очракларда) бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат булып торса (Россия Федерациясе законнары нигезендә проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнү эшләрен башкаручы затның архитектура-төзелештә проектлау өлкәсендә һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителсә). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре төзүче оешмага 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен төзүче оешмага (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ;»;

түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12. дәүләт (муниципаль) милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырган очракта, дәүләт (муниципаль) контрактларны тиешле гавами-хокукый оешма исеменнән төзү һәм үтәү буенча дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге органнар затыннан дәүләт (муниципаль) заказчылар булып торган дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» комос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджетка карамаган фондлар белән идарә итү органы, җирле үзидарә органы һәм әлеге органнар аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән яки әлеге органнар аларга карата тиешле гавами-хокукый оешманың мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр белән (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта) төзелгән килешү;»;

VIII бүлектә:

6-7 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. мөрәҗәгать итүченең төзүче оешма, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендәкаралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче оешма, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт

экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

7. проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүне башкару эшләрен үтәүче зат анда әгъза булып торган архитектура-төзелештә проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче оешмага, техник заказчыга, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче затка тапшыру көненә гамәлдә булган яки дәүләт экспертизасына документларны тапшырган алдагы датадан соң бер айдан артык булмаган чорда гамәлдә булган өземтә, әгәр төзүче оешма, башка зат (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда) бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат булып торса (Россия Федерациясе законнары нигезендә проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнү эшләрен башкаручы затның архитектура-төзелештә проектлау өлкәсендә һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителсә). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре төзүче оешмага 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен төзүче оешмага (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ;»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. хәтәр җитештерү объектының куркынычсызлыгын нигезләү, мондый нигезләүгә сәнәгый куркынычсызлык экспертизасы бәяләмәләре реестрына кертелгән сәнәгый куркынычсызлык экспертизасының уңай бәяләмәсен теркәп, әгәр хәтәр җитештерү объектының куркынычсызлыгын нигезләүне әзерләү һәм мондый нигезләүгә сәнәгый куркынычсызлык экспертизасын уздыру «Хәтәр җитештерү объектларының сәнәгый куркынычсызлыгы турында» 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законда каралган булса;

түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:

«18. дәүләт (муниципаль) милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырган очракта, дәүләт (муниципаль) контрактларны тиешле

гавами-хокукый оешма исеменнән төзү һәм үтәү буенча дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге органнар затыннан дәүләт (муниципаль) заказчылар булып торган дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» комос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджетка карамаган фондлар белән идарә итү органы, җирле үзидарә органы һәм әлеге органнар аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән яки әлеге органнар аларга карата тиешле гавами-хокукый оешманың мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр белән (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта) төзелгән килешү;».

IX бүлектә:

4-5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. мөрәҗәгать итүченең төзүче оешма, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче оешма, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

5. проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүне башкару эшләрен үтәүче зат анда әгъза булып торган архитектура-төзелештә проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче оешмага, техник заказчыга, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче затка тапшыру көненә гамәлдә булган яки дәүләт экспертизасына документларны тапшырган алдагы датадан соң бер айдан артык булмаган чорда гамәлдә булган өземтә, әгәр төзүче оешма, башка зат (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда) бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат булып торса (Россия Федерациясе законнары нигезендә проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнү эшләрен башкаручы затның архитектура-төзелештә проектлау өлкәсендә һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителсә). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре төзүче оешмага 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен төзүче оешмага (техник заказчыга)

тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;»;

түбәндәге эчтәлекле 10-11 пунктлар өстәргә:

«10. проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ;

11. дәүләт (муниципаль) милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырган очракта, дәүләт (муниципаль) контрактларны тиешле гавами-хокукый оешма исеменнән төзү һәм үтәү буенча дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге органнар затыннан дәүләт (муниципаль) заказчылар булып торган дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» комос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджетка карамаган фондлар белән идарә итү органы, җирле үзидарә органы һәм әлеге органнар аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән яки әлеге органнар аларга карата тиешле гавами-хокукый оешманың мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр белән (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта) төзелгән килешү;»;

X бүлектә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе;

5-6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. мөрәҗәгать итүченең төзүче оешма, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче оешма, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

6. проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүне башкару эшләрен үтәүче зат анда әгъза булып торган архитектура-төзелештә проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешма

әгъзалары реестрыннан проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче оешмага, техник заказчыга, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче затка тапшыру көненә гамәлдә булган яки дәүләт экспертизасына документларны тапшырган алдагы датадан соң бер айдан артык булмаган чорда гамәлдә булган өземтә, әгәр төзүче оешма, башка зат (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда) бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат булып торса (Россия Федерациясе законнары нигезендә проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнү эшләрен башкаручы затның архитектура-төзелештә проектлау өлкәсендә һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителсә). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре төзүче оешмага 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле теренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен төзүче оешмага (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. федераль башкарма хакимият органы җитәкчесенең (яисә ышаныч нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе җитәкчесенең, «Роскосмос» космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе җитәкчесенең, «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясе җитәкчесенең, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесе – тиешле бюджет акчаларын баш бүлүче булып торган затның капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп коруның смета бәясен һәм аның егәрлеген төзелеш этаплары буенча бүлүне күздә тоткан этаплап башкару турында барлык этаплар буенча объектны төзү, үзгәртеп коруның гомуми смета бәясенең капиталь төзелеш объектының гомуми егәрлеген саклап, объект төзелешенең билгеләнгән күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәясен арттырмавын раслый торган карары (акты) яисә, төзелеше, үзгәртеп корылышы дәүләт компанияләре һәм корпорацияләре акчасы хисабыннан гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүнең, үзгәртеп коруның аерым этабына карата проект документлары әзерләнгән очракта, – дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) әлеге карары (акты)»;

XI бүлектә:

12-13 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. мөрәҗәгать итүченең төзүче оешма, техник заказчы, РФ Шәһәр

төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче оешма, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

13. архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнүләре өлкәсендә үзеннән-үзе көйләнә торган оешма әгъзалары реестрыннан өземтә, аның әгъзасы булып проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен башкару буенча эшләрне башкаручы, проект документларын тапшыру датасына һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен төзүче, техник заказчыга, инженерлык эзләнүләрен үтәүне тәэмин итүче затка, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда проект документларын әзерләүне тәэмин итүче затка, яисә төзүче, башка зат булса, дәүләт экспертизасына документлар тапшыру датасына РФ ШрК 48 статьясындагы $1^1$ һәм $1^2$ өлешләре белән бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнүләре өлкәсендә үз-үзен җайга салучы оешмада проект документациясен әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эш башкаручының әгъзасы таләп ителгән очракта тапшырыла). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре төзүче оешмага 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче оешмага (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ;»;

22 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«федераль башкарма хакимият органы җитәкчесенең (яисә ышаныч нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе җитәкчесенең, «Роскосмос» космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе җитәкчесенең, «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясе җитәкчесенең, Россия Федерациясе субъекты

дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесе – тиешле бюджет акчаларын баш бүлүче булып торган затның капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп коруның смета бәясен һәм аның егәрлеген төзелеш этаплары буенча бүлүне күздә тоткан этаплап башкару турында барлык этаплар буенча объектны төзү, үзгәртеп коруның гомуми смета бәясенең капиталь төзелеш объектының гомуми егәрлеген саклап, объект төзелешенең билгеләнгән күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәясен арттырмавын раслый торган карары (акты) яисә, төзелеше, үзгәртеп корылышы дәүләт компанияләре һәм корпорацияләре акчасы хисабыннан гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүнең, үзгәртеп коруның аерым этабына карата проект документлары әзерләнгән очракта, – дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) әлеге карары (акты)»;

түбәндәге эчтәлекле 25 пункт өстәргә:

«25. дәүләт (муниципаль) милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырган очракта, дәүләт (муниципаль) контрактларны тиешле гавами-хокукый оешма исеменнән төзү һәм үтәү буенча дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге органнар затыннан дәүләт (муниципаль) заказчылар булып торган дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» комос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджетка карамаган фондлар белән идарә итү органы, җирле үзидарә органы һәм әлеге органнар аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән яки әлеге органнар аларга карата тиешле гавами-хокукый оешманың мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр белән (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта) төзелгән килешү.»;

Административ регламентка 4 нче кушымтада:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле «ж» пункты өстәргә:

«ж. линияле объектның проект документларын әзерләгән очракта, территорияне планлаштыру буенча документация расланган номер һәм документның датасы (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш)

______________________________________________

________________________________________________________

_________________________________________________»;

II бүлек атамасында «инженерлык эзләнү» сүзләреннән соң «РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаруны тәэмин иткән затлар» сүзләрен өстәргә;

III бүлектә:

«төзүче оешма» сүзләреннән соң «РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаруны тәэмин иткән зат» сүзләрен өстәргә;

«Техник заказчы турында идентификация белешмәләре» дигән юлда «, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаруны тәэмин иткән зат турында» сүзләрен өстәргә;

Административ регламентка түбәндәге эчтәлекле 7 нче кушымта өстәргә:

«Проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе җитәкчесенә

___________________________________

Җибәрелү номеры ____, ___________________ ел.

**Техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата (язу хатасы, басма хата, грамматик яисә арифметик хата) турында хәбәр итәм

_____________________________________________________________

(дәүләт хезмәте атамасы)

Язылган:

_____________________________________________________________

_____________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:

_____________________________________________________________

_____________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны (язу, басма хаталарын, грамматик яисә арифметик хаталарны) төзәтүне һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:
1. Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе.
2. ______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________;
3. __________________________________________________________________________.

Техник хатаны (язу, басма хаталарын, грамматик яисә арифметик хаталарны) төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

e-mail:______________ адресына электрон документ рәвешендә;

________________________________ адресы буенча кәгазь документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша.

______________________________________________________________________________.

Раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм минем тарафтан вәкил булган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләр дөрес.

Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | ____________ | (________________________________) |
| (дата) | (имза) | (Фамилия, исем, ата исеме) |